КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 14 апрель г.Казань № 287

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 ел, 27 сентябрь, 856 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлегенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 ел, 27 сентябрь, 856 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлегенә, аны редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 сентябрь, 856 нчы карары белән расланды
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 14 апрель, 287 нче карары редакциясендә)

**Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеге**

| Т/с | Төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төренең исеме |
|---|---|
| 1. | Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге |
| 2. | Махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге |
| 3. | Төбәк дәүләт торак күзәтчелеге |
| 4. | Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлегенә лицензия тикшерүе |
| 5. | Алкогольле продукцияне ваклап саткан өчен лицензия тикшерүе |
| 6. | Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеге |
| 7. | Халыкны һәм территорияләрне төбәк, муниципальара һәм муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге |
| 8. | Төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеге |
| 9. | Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) |
| 10. | Транспорт чараларына техник тикшерү үткәргән өчен түләүнең иң чик күләмнәре үтәлешен тикшерүдә тоту |